**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2026 елның 6 мае** **45-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртипкә карата таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 26-РС нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Рәисенең 2026 елның 9 апрелендәге «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларын һәм Татарстан Республикасы Рәисенең аерым указларын үз көчен югалткан дип тану турында»гы 278 нче номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 26-РС номерлы карары белән расланган (2024 елның 8 апрелендәге 27-РС нче номерлы карар үзгәрешләре белән) Хезмәт (вазыйфаи) тәртипкә карата таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән төзелә. Әлеге акт белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе билгеләнә һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләп үтелә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2. 2.2 пунктының «а» подпунктына «(комиссия рәисе),» дигән сүзләрдән соң «җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары),» дигән сүзләрне өстәргә;

3. 2.4 пунктының икенче җөмләсен чыгарып ташларга;

4. 3.1 пунктының «а» подпунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәр тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының

2009 елның 30 декабрендәге УП-702 нче номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә претензия белдерүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тәкъдим итү хакында Нигезләмәдә күздә тотылган дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим ителү турында;»;

5. 3.7 пунктының «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тәкъдим итү хакында Нигезләмә нигезендә тәкъдим ителгән белешмәләрнең дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көненнән башлап үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы урынбасары Т.П. Борһановага йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы –**
**Совет рәисе:** **И.Ф. Зарипов**